СӘНӘГАТЬ КАЙМАГЫ
Ил икътисадын билгеләгән машина төзелеше халыкның тормыш сыйфатына да нык тәэсир итә

> 2

ЯЛДАН СОҢ
Депутатлар Дәүләт Советының 34 нче утырышына җыелды

> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган документ һәм Дәүләт Советы карарлары

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 140 (28913) | Шимбә | 24 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Төп вакыйга

Россиядә өлешчә мобилизация дәвам итә. Кемнәр китә, ә кемнәр кала? «ВТ» хәбәрчеләре соңгы яңалыкларны барлады, хәрби комиссариатлардагы һәм районнардагы хәлне белеште.

«Үзебез өчен курыкмыйбыз»

Бу вакыйганы төрлечә кабул итүчеләр булса да, беренче көнне үк хәрби комиссариатларга үзе теләп 10 меңнән артык кеше килгән. Дәшмәгән, кулларына чакыру кәгазе тоттырмаган килеш.

Татарстан район-шәһәрләрендә дә Ватан сакчыларын барлыйлар. Казандагы вазгыятьне «ВТ» хәбәрчеләре дә күреп кайтты.

Журналистлар урамында урнашкан Совет районы хәрби комиссариаты ишегалды. «ВТ» хәбәрчеләре килгәндә ыгы-зыгы да, шау-шу да, чират та юк иде. Кулларына кәгазь чакыру тоткан ир-атлар комиссариатка керә тора, чыга тора. Кайсылары ишегалдына урнаша. Араларында инде төрле хәрби бәрелешләрне узганнары да бар. Абзыйлар – офицер дәрәҗәсенә җиткән кешеләр. Җыелу пунктына тормыш иптәшләре белән дә, килгәннәр. Чәй, өй ризыгы белән озатып, күңелләрен күтәреп торалар. Абзыйларның рухлары болай да көр. Кыскасы, (җыелган халык та моны раслый) биредә чыннан да хәрби тәҗрибәсе булганнар җыелган. Бу – ихтыяҗ аеруча булган хәрби белгечлекләр.

– Мобилизация турында ишетүгә әзер булдык инде. Оптимистик кәефне саклыйбыз. Барыргa һәм илне дошманнан азат итәргә кирәк. Кайгыру юк, – диеште алар.

Күңел көрлеген саклап кала алсагыз иде дигән өмет белән, бу хәрби комиссариаттан башкаланың Кулагин урамындагысына юл тоттык. Биредә халык та күбрәк, чагыштырмача – яшьләр. Шулай ук гаиләләре белән килүчеләр бар.

«Хәрби хезмәткә чакыру кәгазен күрсәтикме соң?» Комиссариат ишегалдында карап торышка 35–40 яшьләр тирәсендә булган ир-атлар безгә шулай дип дәште. Журналист булуыбызны чамалап, берсе аралашырга ризалашты тагын. Икенчесе исә телефонына шалтыраткан якын кешесен тынычландырырга ашыкты...

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИЛ ЧАКЫРГАЧ...

Безнең белән әңгәмә корган ир-атка – 35 яшь. Гаиләле, ике баласы бар. Кызы 4 нче сыйныфта укый, ә улына әле 3 ай гына тулып киткән.

– Үзебез өчен курыкмыйбыз. Хәрби хезмәт юлын уздык бит инде, – диде ул. Пешекче булып хезмәт иткән икән. – Күңел халәтен әлегә аңлатып булмый. Яше туры килгәннәр, тәҗрибәсе булганнар чакырылачак инде. Качып калудан мәгънә юк. Бу бит – җинаять эше дә. Тормышка кара тап төшерергә кирәкми. Киләчәк турында да уйларга кирәк. Ярар, менә сез дә рух күтәрергә килгәнсез икән. Гаиләдәгеләргә әллә ни аңлатып булмады. Мондый хәлне аңлатырлык сүзләр дә юк. Аларга борчылмаска гына кала. Күңелләре тыныч булса, безгә дә кыен булмас. Безне әле хәрби өйрәнүләр көтә. Гаиләләребезне ташламасыннар, ярдәм чаралары да булсын иде.

Исән-сау кайтсыннар!

Газетабыз хәбәрчеләре районнардагы хәлләрне дә белеште.

Арча районы башлыгы Илшат Нуриев хәрби хезмәткә чакыру алган егетләр белән очрашып кайткан.

– Бу яңалыкны төрлечә кабул итүчеләр булды. Ни дисәң дә, кунакка чакыру гына түгел бит инде. Әмма күпчелек бу карарның әһәмиятен аңлый, – диде Илшат Нуриев. – Чакыру кәгазе алган егетләр белән очраштык. Сөйләштек, фикерләрен белештек. Үзләреннән бигрәк, гаиләләре өчен борчылалар. Ярдәм кирәк булган очракта аларны игътибарсыз калдырмаячакбыз. Якташларыбыз белән һәрвакыт элемтәдә торачакбыз. Иң мөһиме – исән-сау әйләнеп кайтсыннар.

Тәҗрибә кирәк

Өлешчә мобилизациягә кагылышлы сораулар шактый. Россия Кораллы Көчләре Генераль штабының баш оештыру-мобилизация идарәсе вәкиле Владимир Цимлянский өлешчә мобилизациянең кемнәргә кагылмаячагын аңлатып бирде.

Ахыры 2 нче биттә >

Күбесе – шәхси йортлар

Ел башыннан бирле Татарстанда 12 меңнән артыграк торак йорт калкып чыккан. Тәгаенләп әйтсәк, гыйнвар – август чорында барлыгы 12172 йорт файдалануга тапшырылган. Аларның гомуми мәйданы 2,492 миллион кв. м тәшкил итә. «Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, 126 йортны предприятие һәм оешмалар төзегән. Гомуми мәйданы – 743,1 мең «квадрат». Калган 12046сы – шәхси торак йортлар (гомуми мәйданы – 1 миллион 749,5 мең кв. м).

Торак йортлар төзү буенча Россиянең 10 лидер-төбәге исемлегендә Татарстан бишенче урынга чыккан. Республикадан алда – Мәскәү өлкәсе, Краснодар крае, Мәскәү һәм Ленинград өлкәсе. Исемлеккә шулай ук Санкт-Петербург, Башкортстан, Ростов, Төмән һәм Свердловск өлкәләре кергән. Исегезгә төшерәбез: беренче яртыеллыкта Татарстанда барлыгы 1,91 миллион кв. метрдан артыграк мәйданда торак файдалануга тапшырылган. Шуның 594,5 мең «квадраты» – Казанда.

Табиблар кайтты

Татарстанга 25 медицина хезмәткәре кайтты. Алар махсус хәрби операция зонасында хәрбиләрнең һәм Луганск Халык Республикасында яшәүчеләрнең гомере өчен көрәшкән. «Татар-информ» агентлыгы хәбәр иткәнчә, Республика клиник хастаханәсеннән һәм Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсеннән җибәрелгән табиблар, фельдшер, хирург, йөртүчеләр бу. Сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков медицина хезмәткәрләрен «түгәрәк өстәл» янына җыеп, һөнәри бурычларын уңышлы үтәүләре өчен аларга рәхмәт белдергән. Министр әйтүенчә, медикларның барысы да бүләккә тәкъдим ителәчәк.

Кама елгасына чират

Татарстанда Кама елгасын савыктыру программасы пәйда булырга мөмкин. Иделне савыктыру проектына охшаш булачак ул, дип белдергән экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков. Республика һәм Кама елгасы ярында «утыручы» башка төбәкләр тәкъдим иткән программа федераль дәрәҗәдә хупланган. Хәзер бердәм проект эшләнелә. «Татарстанда Кама 300 чакрымнан артыграк ераклыкка сузылган, шуңа күрә проект безгә бик кирәк. Ул Россия сулыклары торышын яхшыртуга юнәлдерелгән. Аңа Идел, Кама һәм Россиянең башка зур елгаларын савыктыру чаралары кертеләчәк», – дигән министр.

Вазгыять һәм гамәл

Эшләре тотрыклы

ТАТАРСТАНДА БАНК СИСТЕМАСЫН ҮСТЕРҮ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

Дустанә булмаган илләргә ышаныч юк, үз көчеңә таянырга кирәк. Казанда узган «XXI гасыр Россия банклары» халыкара банк форумында бу фикерне еш ишетергә туры килде. Форумда катнашучылар килеп туган вазгыятьтә илнең банк тармагын үстерү, камилләштерү юлларын эзләде. Шактый саллы тәкъдимнәр дә яңгырады.

Әйтик, өлешчә мобилизациядә катнашучыларның кредит буенча түләүләре кичектереп торылырга мөмкин. Белгечләр SWIFT халыкара түләү системасыннан тулысынча баш тартып, исәп-хисапларны милли валютада гына башкару да яклы.

Унтугызынчы тапкыр уздырылучы форумның быелгысы Казанда үтте. Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов фикеренчә, халыкара форумны уздыру урыны итеп нәкъ менә Казанны сайлаулары юкка түгел.

– Бүген Татарстан, Мәскәү белән Санкт-Петербургтан кала, төбәк банклары сакланып калган бердәнбер төбәк булып тора. Соңгы елларда шактый төбәк банклары ябылды бит. Икенчедән, киләсе елдан Россиянең банк системасына ислам финансларын гамәлгә кертү буенча тәҗрибә башланачак. Анда Татарстан да катнашачак. Безнең республикадан башка ислам финансларын уңышлы гына гамәлгә кертеп булмаячагы көн кебек ачык, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында ислам банкингы юнәлешендә республиканың тәҗрибәсе барлыгын искәртте. «Татарстан ислам банкингының күп кенә алымнарын сынап карар, аларны

башка төбәкләрдә дә кулланып булыр дип ышанам», – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов белдерүенчә, банк тармагы яңа шартларда икътисад үсешенә бик нык ярдәм итә.

– Хәзерге вакытта барлык төр кредитларның 37 процентын кече һәм урта эшмәкәргә бирелгәннәре тәшкил итә. Бу сан югарырак булырга тиеш, чөнки кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы вазгыять үзгәрешләренә сыгылмалы җавап кайтара, халыкны эш белән тәэмин итә, – ди Президент.

Рәсми саннарга күз салсак, бүген республика оешмалары, халыкка бирелгән кредит күләме 1,4 трлн сумнан артып китә. Шуларның 380 млрд сумын торак сатып алырга һәм төзелеш тармагына ярдәм итәргә мөмкинлек биргән ипотека кредитлары, 60 млрд сумнан артыгын – агросәнәгать комплексы кредитлары, 250 млрд сумнан артыгын эшкәртү тармагы кредитлары тәшкил итә.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Рамил КУРАМШИН, Татарстанның халык артисты, баянчы:

Гармуннарның төрлесе бар. Кайсы әче телле, яңгырашы ягыннан татарга килешми торганнары бар. Хәзер тальянга берьяклы авыштылар. «Тальянда гына моң» диючеләр белән килешеп бетмим, ә менә баянда нинди генә бормалар чыгармыйсың – татар моңын тулысынча баянда күрсәтеп була.

(«Татар-информ»)

РОССИЯДӘ – COVID-19

Коронавируска каршы оператив штаб COVID-19 чиренә бәйле соңгы мәгълүматлар белән уртаклашты.

РОССИЯДӘ

53335 яңа очрак / **3915** кеше хастаханәдә

104 кеше үлгән / **57625** кеше сәламәтләнгән

ТАТАРСТАНДА

840 яңа очрак

1042 кеше сәламәтләнгән

108 кеше хастаханәдә

Гөрли сәүдә

Бүген Казанда – барлыгы 15 мәйданчыкта авыл хуҗалыгы ярминкәләре уза. Республиканың 22 районы һәм 18 авыл хуҗалыгы предприятиесе сәүдә урыннарына үзләренең продукциясен китерде. Сәүдә иртәнге алтыдан көндезге уникегә кадәр дәвам итә. Анда чагыштырмача арзан бәядән сыйфатлы яшелчә һәм ит ризыклары, ярдәмче хуҗалык, бакча өчен кирәк-ярак сатып алу мөмкинлеге бар.

Исегезгә төшерәбез: ярминкәләр Казанда 10 сентябрьдә башланып китте. Алар 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Сәүдә нокталарында җәмәгать тәртибе, юл хәрәкәте иминлеге саклана. Ярминкәгә килүчеләргә, коронавирус таралуны булдырмас өчен, социаль дистанцияне онытмау тәкъдим ителә.

kzn.ru

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Алтын багана»: тәбәнәкме, биекме?

Иртәгә – Машина төзүчеләр көне. Икътисадның «алтын баганасы» булган, һәрхәлдә, булырга тиешле тармакта хезмәт куючылар, илнең иртәгесе өчен тырышучы, булган абруен тотып торганнарның һөнәри бәйрәме иртәгә.

Машина төзелеше ул – кайберәүләр уйлаганча, автомобильләр җитештерү генә түгел, ә теләсә нинди икътисадның үзәге, илдәге индустриянең төп өлеше, бар булган сәнәгатьнең каймагы. Әлеге юнәлешкә металлургия өчен авыр машина-механизмнар җитештерүдән башлап, транспорт төзелеше (очкычлар, локомотивлар, суднолар төзү), станоклар ясауны да кертеп, приборлар, электрон җиһазлар, ягъни төгәл машина төзелешенә (точное машиностроение) кадәр барысы-барысы да сыйган. Машина төзелеше ул космик аппаратлар да, атом-төш реакторлары да, бер үк вакытта тузан суырткыч һәм кер юу машиналары җитештерү дә. Бу комплекслы тармак, башка юнәлешләрне (мәсәлән, нефть, газ чыгаруны) төрледән-төрле җайланмалар, җиһазлар белән тәэмин итеп кенә калмый, үсештә булган җәһәттә, илдәге фәнни-техник алгарышны да билгели, аны камчылап тора. Ил икътисадын, аның торышын, сыйфатын билгеләгән машина төзелеше, ахыр килеп, халыкның тормыш дәрәҗәсенә дә нык тәэсирле. Тармак үскән, үзенә бар үзенчәлекләрне дә сыйдырган икән, гражданнар да рәхәт яши дигән сүз. Башкача әйткәндә, үзен хөрмәт иткән, яшәүнең җиңел юлларын эзләмәгән теләсә кайсы ил күз уңында тотарга тиешле абруйлы юнәлеш ул машина төзелеше.

2011 елның җәендә ил җитәкчелеге: «Без киләчәк 10 ел эчендә Россияне дөньяның иң көчле биш икътисады (биш иле) эченә кертергә тиеш», – дип белдергән иде. Ягъни беренче бишлектә булган илләрнең (АКШ, Кытай, Япония, Германия, Бөекбритания) берәрсен исемлектән кысрыклап чыгарып, аның урынын алырга. Теләкләр зурдан иде. Юлы да бер – теләсә кайсы икътисадчы, сәнәгать белгече андый нәтиҗәгә ирешер өчен беренче чиратта без бүген сөйләшкән тармакны – машина төзелешен үстерү зарурлыгын әйтәчәк. Чөнки алга киткән илләрдә сәнәгать продукциясенең 45–50 проценты нәкъ менә шул тармакка туры килә. Россиядә бу сан 2011 елдан соң 11 ел узып та, җәмгысы 15 процент кына. Илләр рейтингында да ничек 11 нче баскычта булсак, хәзер дә шунда торабыз. Ни аяныч, Канада, Италия кебекләрне артка калдырып, бер-ике урынга өскә күтәрелә, беренче унлыкка да уза алмадык. Чималга бәйлелек әллә каныбызда шунда, әллә тиешенчә теләмибез, әллә булдыклылык җитми – бишлеккә эләгү бүген дә хыял гына булып кала. Биредә шунысын искәртү дә кирәктер: дәүләтләрнең икътисади рейтингы тулай эчке продукт (ВВП) күләме буенча билгеләнә һәм без яшәгән илдә ул 1,7–1,9 триллион доллар тәшкил итә. АКШ, Кытай, Япония дигәндә саннарның 23, 16 һәм 6 триллион доллар икәнен искәртик.

Тулай эчке продуктка, илләр рейтингына кереп киткәч, Япониягә аерым тукталасы килә. Күпләр бәлки белеп тә бетермидер, Кытай күтәрелгәнче, Кояш чыгышы иле дүрт дистә ел буе (1968–2010 еллар) дөньяның икенче икътисады булып яшәде. Эчке продукт дигәндә ул бары АКШтан гына калышты. Күз алдына гына китерик: Икенче Бөтендөнья сугышында җиңелгән, ул гынамы, репарацияләр (җиңелгән як җиңүчеләргә түләргә тиешле ясак-компенсация) нигезендә соңгы станогы, соңгы балык тоту траулеры, ятьмәләренә тикле тартып алынган ил барлы-юклы чирек гасыр эчендә нигезендә машина төзелеше яткан көчледән дә көчле икътисад булдырсын әле. Утрауларда бернинди файдалы казылмалар, нефть, газ, күмер, башкасы булмаган килеш. Ләкин дөньяны шаккатырган япон могҗизасы реаль күренеш иде. Сәнәгатьнең асыл өлеше – машина төзелеше чәчәк атсын өчен рациональ акыл, көчле теләк һәм эш сөйгән куллар гына кирәк икән бит. Японнар ясаган ышанычлы автомобильләр, ярты дөньяга сатылып торган төзелеш һәм юл төзү техникасы, төрле тоннаждагы суднолар, станоклар, аларның бар җиһанга таралган электроникасы – бөтенебез белгән брендларны санныйсы да саныйсы.

Станок төзелеше (станкостроение) дигәч, тагын үзебезнең тарафлар, биредәге вазгыять искә килә. Машина төзелешенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе булган тармак без яшәгән илдә инде ничә еллар авыр хәлдә. Нефтьчеләребездә хезмәт куеп, нефть табу җиһазлары җитештерү һәм төзәтү белән шөгыльләнгән оешмада эшләп йөргәндә, фәкыйрегез катлаулы станоклар, электрон идарәсе булган технологик җиһазлар, аларның төзеклеге өчен җаваплы иде. Күпме генә төзек тотарга тырышма, станок, җиһаз паркы туза, ул барыбер даими яңартылып торуга мохтаҗ. «Кара алтын» табучы берләшмәдә акчага кытлык юк – алар яңартылды да. Тик менә мин тир түккән дистә ярым ел эчендә оешма сатып алган станоклар, катлаулылары гына түгел, гадиләре дә башлыча чит илләрнеке, ни хикмәт, шул ук Кытайныкы булды. Шул елларда ук станок төзелеше дип аталган мөһим юнәлешнең «утырган»лыгын Рязань станок җитештерү заводына эш төшеп барып чыккач күргәннәр – ярым буш цехлар, кайсы кая качышып беткән белгечләр дә расламады түгел, раслады.

Россиядә машина төзелеше бар булган сәнәгатьнең 15 процентын тәшкил итә, дидек. Сүз уңаеннан Татарстаныбызда аның 25 процент икәнен билгеләп, республикабыз өчен бераз горурланып алыйк. Әлеге санны КамАЗ, КВЗ, КАПО, «Компрессормаш», Горький исемендәге суднолар төзү заводы кебек предприятиеләребез бирә. Горурланган җәһәттә дә ул санны тагын да арттыру зарурлыгы да ачык. Ил масштабында индустрияләштерүгә гомуми юнәлеш алынган очракта, аны санаулы еллар эчендә башкарып чыгып та булыр иде. Вә ләкин ил элекке рельслар буенча хәрәкәт иткәндә, аерым бер төбәккә бик теләгәндә дә аны ике тапкыр зурайту авыр…

Нефть, газ китергән миллиардларга таянып индустриаль рельсларга басарга, киләчәктә шулар буйлап хәрәкәт итәргә нәрсә комачаулый безгә? Комачау күренми. Миңа калса, теләк җитенкерәми. Яңа технологияләргә нигезләнгән яңа завод салу иртәгә үк өеп табыш китерми. Ул берничә елдан соң гына үзен аклый торган ярыйсы озын проект. «Алтын багана»ны өч тапкыр биегрәк итәр өчен шул ук машина төзелешенә дәвамлы инвестицияләр кирәк. Тик хикмәт шунда: чималчылык бозган бездәге капитализмга акча тиз әйләнсен – бүген үк булсын. Алар күтәргә өйрәнмәгән. Холык-фигыль, менталитетны үзгәрткән, яңа технологияләргә табына башлаган, бер үк вакытта дөньяви кооперациядән дә баш тартмаган җәһәттә генә безне уңыш көтә, диясе килә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Сезнең кулда – халык сәламәтлеге һәм ил иминлеге. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Роспотребнадзор вәкилләре белән очрашуда шулай дип белдерде. Искәртеп үтик: идарә үзенең 100 еллыгын билгеләп үтә.

Тантанага кадәр Рөстәм Миңнеханов Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хезмәткәрләренә «Лада» автомобиле ачкычларын тапшырды.

– Пандемиянең кырыс шартларында оперативлык һәм чараларны үз вакытында уздыру актуаль кала. Бу машиналар Роспотребнадзор хезмәткәрләренең көндәлек эшендә кулланылачак, – диде республика җитәкчесе. Барлыгы 10 машина ачкычы тапшырылды.

Роспотребнадзор хезмәткәрләрен котлау тантанасында исә республика Президенты аларның бер гасыр дәвамында илебезнең гигиена һәм санитар куркынычсызлыгын тәэмин итүен, иң катлаулы һөнәри һәм оештыру бурычларын хәл итүләрен искәртте.

– Арттырмыйча әйтә алабыз: сезнең кулда – халык сәламәтлеге, димәк, дәүләт иминлеге дә. Юбилей алдыннан сезнең эшегезне ил башлыгы Владимир Путин да югары бәяләде, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Коронавирус пандемиясе вакытында шуңа инандык: икътисад өчен аз гына чир дә куркыныч булырга мөмкин. Пандемия чоры сезнең хезмәтнең никадәр мөһим булуын раслады.

Уртак эшчәнлеккә йомгак ясап, Рөстәм Миңнеханов сәламәтлек саклау тармагын замана таләпләренә карап үзгәртеп кору, төп икътисади тармакларның эшен өзлексез рәвештә оештыру мөмкин булуын әйтте. «Инфекцияләргә каршы профилактик эштән кала, сезгә даими рәвештә су, һава, азыктөлек, хезмәт шартларын, балалар иминлеген дә кайгыртырга туры килә», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Россия табигый байлыклар һәм экология министры Александр Козлов белән очрашты. Президенттан тыш, очрашуда Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы (Рослесхоз) җитәкчесе Иван Советников һәм Россия Табигать һәм Татарстан министрлыкларыннан башка вәкилләр катнашты.

Очрашу барышында Татарстанда «Экология» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырыла торган «Уникаль су объектларын саклау» һәм «Иделне савыктыру» федераль проектлары мәсьәләләре тикшерелде. Шулай ук Рөстәм Миңнеханов һәм Александр Козлов су объектларының ярларын ныгыту, республика елгалары буенда су саклаучы урманнар утырту һәм башка актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышты.

Котлау

Бик зур көч сез!

Бүген – Татарстан профсоюзлары көне. Бу уңайдан республикада яшәүчеләрне Премьер-министр Алексей Песошин котлады.

«Профсоюзлар хезмәт коллективлары, эш бирүчеләр белән Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасындагы күпер буларак, хезмәт ияләренең хокуклары һәм мәнфәгатьләрен яклап, республикабыз хезмәтчәннәренең зур армиясе мәнфәгатьләренә кагылышлы мөһим карарлар кабул итүгә зур йогынты ясардай көч булып тора, – диелә котлауда. – Профсоюз оешмалары, актив позициясе, һөнәри компетентлыгы, максатка ирешүдәге ныклыгы нәтиҗәсендә, хезмәт коллективларының, шулай ук социаль партнерлык якларының ихтирамын тоеп яши.

Һөнәри берлекләр республикадагы социаль партнерлык системасы кысасында хезмәткәрләрнең хокукларын актив төстә яклап килә.

Төрле яклап уйланылган эшегезнең алга таба да республикада яшәүчеләрнең тормышын яхшыртуга ярдәм итәчәгенә ышанам.

Гомуми эшкә тугрылыгыгыз өчен, барлык хезмәт ияләренең хокукларын яклауны тәэмин итүегез өчен рәхмәт белдерәсем килә. Сезгә нык сәламәтлек, иминлек, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт, уңышлар телим!»

Сәнәгатьнең «йөрәге»

Иртәгә – Машина төзүчеләр көне. Бу уңайдан тармак хезмәткәрләрен һәм ветераннарын Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин котлады.

«Һөнәри бәйрәмегез уңаеннан эчкерсез котлауларны кабул итегез, – диелә котлауда. – Машина төзелеше теләсә кайсы индустриянең «йөрәге» булып тора. Инновацион үсеш юлын һәрдаим камилләшү, фән һәм техниканың өр-яңа казанышлары белән бергә атлау теләгеннән башка гына күз алдына да китереп булмый. Татарстан Республикасы мөмкинлекләре заманча икътисадның мондый таләпләренә тулысынча җавап бирә. Югары дәрәҗәдә профессионализм, гаять зур фәнни һәм техник мөмкинлекләр, төптән уйланган идарәи карарлар һәм Татарстан машина төзүчеләренең сөекле эшләренә тугрылыгы – яңа базарлар яулау һәм инновацияләрне гамәлгә кертү өчен ышанычлы нигез. Бүгенге гаять катлаулы сәяси һәм икътисади вазгыятьтә финанс тотрыклылыгын, сәнәгать үсешен тәэмин итү мәсьәләләрендә машина төзелеше тармагы роле күп тапкыр арта.

Машина төзелеше предприятиеләренең барлык эшчеләре, инженерлары һәм хезмәткәрләренә намуслы хезмәте, һөнәргә тугрылыгы, республика икътисадын үстерүгә керткән зур өлеше өчен рәхмәт белдерәм. Нык сәламәтлек, җитештерүдә уңышлар, тынычлык, иминлек, иртәгесе көнгә ышаныч телим!»

Ил чакыргач...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Хәрби хезмәткә бронь алган кешеләрне чакырмыйлар. Андыйлар сафына, әйтик, оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләрендә эшләүчеләр керә. Сәламәтлеге аркасында хәрби хезмәткә вакытлыча яраксыз булганнарны да бурыч үтәргә чакырмыйлар. Гаиләдә үзенең якынын яки I группа инвалидны даими караучылар, 16 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк баласы булган кешеләр дә өлешчә мобилизациягә эләкми. Әгәр ир-егетнең әнисе, аннан кала тагын дүрт һәм күбрәк баланы ялгызы гына тәрбияли икән, мондый кеше дә хәрби хезмәткә чакырылмый. Чит илгә чыгып йөрүчеләр мәсьәләсендә дә ачыклык керттеләр. Әгәр андый кеше даими рәвештә башка илдә яши икән, аларга өлешчә мобилизация кагылмый. Әмма вакытлыча гына киткән һәм хәрби исәптә торган кеше хәрби хезмәткә чакырылырга мөмкин.

Инде алдан ук әйтелгәнчә, хәрби хезмәткә армия тормышын күреп кайткан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашу тәҗрибәсе һәм белгечлеге булган кешеләр алына. Беренче чиратта атучылар, танкистлар, артиллеристлар, йөртүчеләр, механикларга игътибар итәчәкләр. Өстенлек званиегә түгел, ә белгечлеккә биреләчәк. Мобилизациягә эләгүчеләргә контракт буенча хезмәт итүчеләр өчен каралган хезмәт хакы һәм ташлама вәгъдә итәләр. Акчаны исә аларның туганнарына да җибәрү мөмкинлеге бар. Пәнҗешәмбе көнне дөнья күргән Хөкүмәт карарында хәрби хезмәткә киткән кешенең эш урыны сакланачагы әйтелә.

Тәртип булсын!

Бу эштә өзеклек килеп чыкмасын өчен республикада хәрби комиссариатларга өстәмә ярдәм күрсәтәчәкләр, транспорт мәсьәләсендә булышачаклар. Татарстан Президенты, республика чакырылыш комиссиясе рәисе Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинетында узган район һәм башлыкларына әнә шундый күрсәтмә бирде. Моннан тыш, җыю пунктларында туклану, медицина хезмәтен күрсәтү, тәртип саклау мәсьәләләренә аерым игътибар биреләчәк. Президент җаваплы барлык структуралар катнашында көн саен селектор киңәшмәсен үткәрергә кушты. Бүлек җитәкчеләре анда шәхсән катнашачак. Вазгыять буенча оператив мәгълүматны көн саен Татарстан Президентына хәбәр итеп торачаклар.

Кемнәр чакырылмый?

Хөкүмәтнең «Телеграм-канал»ындагы мәгълүматларга караганда, түбәндәге өлкәләрдә эшләүчеләр хәрби хезмәткә чакырылмаячак:

✓IT өлкәдә эшчәнлек алып баручы, мәгълүмат инфраструктурасы эшчәнлеген тәэмин итүче аккредитацияләнгән оешмаларда эшләүчеләр;

✓Россия элемтә операторлары булып торучы, мәгълүматлар эшкәртү үзәкләрен, шулай ук гомуми файдаланудагы элемтә челтәре һәм элемтә чараларын кертеп, аерым элемтә корылмалары эшенең иминлеген тәэмин итүче оешмаларда эшләүчеләр;

✓мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендәге төп оешмаларда, редакцияләрдә, теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларында, телеканалда, радиоканалда эшләүчеләр, массакүләм мәгълүмат чараларын җитештерүгә һәм (яки) таратуга җәлеп ителүчеләр;

✓илкүләм түләү системасының, финанс базарының, тере акча әйләнешенең тотрыклылыгын тәэмин итүче оешмаларда эшләүчеләр.

БАЛАҢ КУЛЫНДА НӘРСӘ БАР?

ТР Дәүләт Советында

VI чакырылыш Дәүләт Советының 34 нче утырышында колак торгызырлык мәсьәләләр күтәрелде. Бюджет турындагы законга үзгәрешләр кертү буенча артык сүз куертып тормадылар үзе. Әледән-әле төрле санкцияләр кертелүгә карамастан, республика казнасы турында артык борчылырга сәбәп юк икән.

Финанс министры Радик Гайзатуллин әйтүенчә, бюджетка салым һәм салым булмаган керемнәр күләме 48,4 млрд сумга артырга тиеш. Оешмалар табышына планлаштырылган салым да 33,6 млрд сумга артыр дип фаразлана. Бу «муллык» нигездә нефть табу һәм эшкәртү компанияләре, сәүдә оешмалары эшчәнлеге хисабына барлыкка киләчәк. Әлбәттә, казнаның чыгым өлеше дә 22,5 млрд сумга артачак.

Бүгенге шактый буталчык заманда артыгын фаразлап булмый да инде ул. Шулай да узып баручы финанс елында бөтен йөкләмәләр дә үтәләчәк, диделәр. Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин әйтүенчә, Президент та, Хөкүмәт тә Татарстан икътисадына аеруча игътибар итә, икътисадны тотрыклы итү өчен барлык чаралар күрелә. Бюджет кытлыгын киметү буенча да планлы эш алып барыла.

Министр Радик Гайзатуллин, бюджет кытлыгы 9,5 млрд сум булачак һәм ул финанс чыганаклары белән тәэмин ителгән, диде.

Кыскасы, артык бәргәләнергә нигез юк. Депутатларны иң борчыган ике мәсьәлә турында аерым язарга тиешбез. Беренчесе балигъ яшькә җитмәгәннәргә аерым тауарларны сатуны чикләү турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәреш кертү турында иде. Закон проекты белән республика прокуроры Илдус Нәфыйковның таныштыруы үзе үк сагайтты.

Хәзерге көндә яшүсмерләр энергетик эчемлекләрне мулдан куллана башлаган. Аларда кофеин, шикәр, витаминнар, аминокислоталар һәм үсемлек матдәләре гади продуктлардагы белән чагыштырганда күпкә артык икән. Кофеинның югары дозалары балалар, яшүсмерләр өчен аеруча хәтәр.

2014 елда Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы энергетик эчемлекне кирәгеннән артык куллануның нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин икәнлеге турында хәбәр иткән иде инде. Болар борчылу, ярсу хисләре арту, йөрәкнең бик еш тибә башлавы, артериаль басым күтәрелү, ашказанына зыян килү, паника һөҗүмнәреннән курку, шикәр авыруы барлыкка килү һәм башкалар.

Депутатларга тәкъдим ителгән закон проектында балигъ булмаганнарга кәефне күтәрә торган алкогольсез эчемлекләрне ваклап сатуны чикләү, закон бозучыларны җавапка тарту каралган. Прокурор әйтүенчә, хәзерге көндә яшүсмерләр арасында сниффинг, ягъни токсик исерү дә тарала башлаган. Монысы кабызгычларга газ салу өчен кулланыла торган кечкенә баллоннар, туристик газ плитәләрен эшләтү баллоннары эчендәге углеводород газларын сулауга бәйле. Әлеге тауарларны сату чикләнми һәм үсмерләр аларны «кәеф күтәрү» өчен файдалана икән. Газ иснәп исерүчеләр арасында үлүчеләр дә бар ди. Татарстан хокук саклау органнары һәм медицина оешмалары газ иснәп агуланганнарны, җан тәслим кылганнарны теркәп баралар икән үзе. Әмма теркәп кенә тере калып булмый шул.

Шунысы сәер: әле 2013 елда ук Россия Думасына энергетик эчемлекләрне сатуны тыю турында закон проекты кергән булган. Проект авторлары бу эчтәлектәге законның Төркиядә, Даниядә, Норвегиядә, Исландиядә, АКШның берничә штатында инде кабул ителүен дә әйткәннәр. Әмма Думада әлеге закон проектын ни өчендер гел кире борып килгәннәр. «Ни өчендер» дигәне шул инде, депутатлар «тонус бирә торган алкогольсез эчемлек» дигән төшенчәне аңлап бетермәгәннәр, аныкларга кирәк, дигәннәр, имеш. «Яшен яшьнәмичә мужик чукынмый» бит инде ул, ниһаять, агуланулар һаман арта торып, үлем-китем очраклары да ешая башлагач, әлеге афәтнең яшь буынга нинди зыян салуын аңладылар. Шунысын да әйтик: Россиянең кайбер төбәк парламентлары энергетик эчемлекләрне тыю яки чикләү турында закон кабул иткән икән инде, тик Россия Думасы гына ашыкмый. Безнекеләр мондый закон проектын кабул итеп Мәскәүгә дә мөрәҗәгать итмәкче. Һәрхәлдә, Дәүсовет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шул фикердә. Чөнки яшь буынның сәламәтлеге өчен куркыныч булган эчемлекне бер җирдә тыюдан, икенче җирдә рәхәтләнеп сатудан бернинди файда булмаячак.

«Тонус күтәрүче» эчемлек турында сөйләшү депутатларның күңелен кузгатты. «Бала кулында бүген сырага хәтле бар», – диючеләр дә булды. Энергетик эчемлекләрнең бөтен җирдә иртән иртүк сатылуын, балаларның юл уңаеннан шуларны сатып алуын һәм мәктәпкә «күтәренке күңел» белән барып керүләрен дә сөйләделәр.

Үсмерләрне спортка күбрәк тарту, ата-ана белән күбрәк эшләү кирәклеген дә онытмадылар. Әлеге эчемлекне җитештерүчеләрне гаепләүчеләр дә булды. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, хикмәт энергетик эчемлекләрне тыюда гына түгел. Без аларны куллануны чикләү турында уйланырга тиеш. Һәм депутатларга уйланыр өчен бераз вакыт бирелде. Димәк, закон проектына өстәмәләр, үзгәрешләр керәчәк әле.

Утырышта күтәрелгән икенче мәсьәлә дә «киләчәгебез чәчәкләре» – үсмерләр язмышына бәйле. «Хөкүмәт сәгате»ндә Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева күзәтүчесез калган балалар язмышы һәм алар арасында тәртип бозуларны булдырмау турында чыгыш ясаган иде. Аның соңгы 8 ай эчендә генә дә 14 үсмернең үз-үзенә кул салуы турында әйтүеннән һәркемнең чәчләре үрә торгандыр, мөгаен. Әле моның өстенә үз-үзенә кул салырга омтылуның алтмыштан артык очрагы булуын, бәхеткә, балаларның исән калуларын әйтте ул.

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН:

«Безнең көч – бер йодрыкка туплануда»

Дәүләт Советы утырышында депутат Эдуард Шәрәфиев махсус хәрби операцияне хуплап белдерү ясады.

Парламентчы, килеп туган хәлләрне өйрәнеп, Татарстаннан мобилизацияләнүчеләрне матди яктан тәэмин итүгә булышырдай депутат комиссиясен оештырырга чакырды. Эдуард Шәрәфиев әйтүенчә, районнарда, мобилизацияләнүчеләрнең гаиләләренә ярдәм итү өчен, махсус эш төркемнәре оештырырга кирәк. «Үз бурычларын үтәргә китүчеләр өйләрендә барысы да тәртиптә икәнен белеп торырга тиеш», – диде депутат. Эдуард Шәрәфиев шулай ук, кирәк булса, повестка алган очракта, Ватанны сакларга әзер булуын белдерде.

– Ил Президенты, Башкомандующий әйтүенчә, хәлләр катлаулы, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, депутатларга мөрәҗәгать итеп. – Илебезнең мөстәкыйльлеген саклау турында сүз бара. Махсус хәрби операция Украина түгел, ә Украина территориясендә Көнбатыш илләре белән алып барыла.

Дәүләт Советы Рәисе шулай ук депутатларны аңлату эшен көчәйтергә, сайлаучылар янына барып, вазгыятьне аңлатырга чакырды. «Кыю булыгыз, – диде ул, – шикләнүчеләрне яки махсус хәрби операциягә каршы булучыларны дөрес фикер йөртмәүләренә инандырыгыз, алар белән сөйләшегез. Безнең көч – бер йодрыкка туплануда. Ватанны сакларга кирәк».

Бу гайре табигый хәлнең сәбәпләрен аңлату өчен бер-ике сүз генә җитмидер. Шәхсән үзем моны замана зәхмәте дип кабул иттем. Беренчедән, үз-үзенә кул салган балаларның әти-әниләре, нигездә, 90 нчы елларда туганнар. Бу – җәмгыятьнең әхлакый яктан үзгәрә башлаган вакыты. Ә бу үзгәреш шактый ук дәрәҗәдә тормыш уңайсызлыкларына бәйле. Кайбер депутатлар әйтмешли, ул елларда шактый гаилә исән калу өчен тырышкан, бала тәрбияләү икенче планга күчкән. Кайбер гаиләләрдә үзара мөнәсәбәтләрнең ямьсез төсмерләр алуын Ләйлә Фазлыева да яшерми, шул ук вакытта баланың үз-үзенә кул салуы гаиләнең хәерчелегенә турыдан-туры бәйле түгел, ди.

Республикада Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, урыннарда аның бүлекчәләре бар. Ләйлә Фазлыева фикеренчә исә, суицидизмны без күп ведомстволар бергәләп эшләсә генә бетерә алабыз. Ни әйтик, дөрес сүзгә җавап юк, диясе генә кала. Фәрит Мөхәммәтшин исә депутатларны да әлеге проблема белән ныклап шөгыльләнергә чакырды.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы 1 кисәге 11 пунктына туры китереп, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22 һәм 23 статьялары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11 һәм 12 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзалары итеп билгеләп куярга:
Вәлиуллин Илшат Ришат улын;
Вәлиуллова Рәшидә Рафикъ кызын;
Кондратьев Андрей Станиславовичны;
Кудряшов Андрей Витальевичны;
Куралов Эрик Рудольфовичны;
Нефедов Андрей Александровичны;
Сергеева Гөлнара Илдус кызын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 23 сентябрь № ПУ-661

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1564-VI ДС

Гыйниятуллина Светлана Владимировнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Гыйниятуллина Светлана Владимировнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1565-VI ДС

Пименова Наталья Николаевнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Пименова Наталья Николаевнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1566-VI ДС

Әхмәтҗанов Ленар Илдар улын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Әхмәтҗанов Ленар Илдар улын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1567-VI ДС

Борисова Надежда Петровнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Борисова Надежда Петровнаны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1568-VI ДС

Видисенков Сергей Васильевичны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Видисенков Сергей Васильевичны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1569-VI ДС

Җиһаншина Альбина Реваль кызын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп кую турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 24 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Җиһаншина Альбина Реваль кызын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләп куярга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1570-VI ДС

БЕРЛӘШҮ ХАКЫНА

Киләчәкне үзләре сайлый. Донецк һәм Луганск халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә Россия составына керү турында референдум башланды. Тавыш бирү 23 сентябрьдән 27сенә кадәр дәвам итәчәк.

Моңа кадәр уздырылган сораштырулар барышында ДНРда халыкның – 94, ЛНРда – 93, Запорожье өлкәсендә – 87, Херсонда 80 проценты Россиягә кушылу яклы булуын әйткән. Бу атнада әлеге мәсьәләдә үз фикерен Россия Президенты Владимир Путин да җиткерде. «Алар кабул иткән карарны хуплаячакбыз», – диде ул халыкка мөрәҗәгатендә.

Татарстан да әлеге референдумнан читтә калмый. Тавыш бирү көннәрендә республиканың өч шәһәрендә сайлау участоклары эшли. Алар Казанда, Чаллы һәм Әлмәттә ачылды.

Бу вакыйганың әлеге дүрт төбәк һәм Россиянең бүгенгесе һәм киләчәге өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын белгечләрдән сораштык.

Андрей Большаков, КФУның социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институтының конфликтология кафедрасы мөдире:

– Референдумнар үткәрү – кешеләрнең иминлегенә бәйле саклагыч чара. Россиянең әлеге позициясен Президент яңгыратты инде. Беренчел сораштыру нәтиҗәләренә караганда, бу территорияләрдә яшәүчеләрнең күпчелеге безнең ил составына керү фикерен яклап тавыш бирергә җыена. Россиядә яшәүчеләрнең дә күпчелеге бу позиция яклы. Димәк, әлеге территорияләр Россия составына кергән очракта, җирле халык хөкүмәтнең генә түгел, гади халыкның да ярдәмен тоячак. Ә бу – бик мөһим. Әлбәттә, төрле фикерләр бар. Һәм моны аңларга да була. Хәзер халыкның кәефе тотрыксыз. Безгә каршы махсус эшләүчеләр бар. Аларга бөтен ил территориясендәге вазгыятьне тотрыксызландыру отышлы. Шуңа да рәсми чыганакларны тыңларга киңәш итәм.

Гадәттә референдумнар тыныч чакта була. Шулай да бөтен кагыйдәләр дә үтәлер дип уйлыйм. Бар кеше дә үз фикерен белдерәалсын өчен, алар биш көн дәвам итәчәк. Барысы да халыкара хокук нормаларына туры китереп эшләнә.

«Татар-информ»

Республиканың иҗтимагый һәм патриотик оешмалары Казанның Җиңү паркында оештырган митингка 8 мең кеше җыелды. «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз» шигаре астында узган чарада катнашучылар Россия Президенты карарларына һәм Россия Кораллы Көчләренә теләктәшлек белдерде.

Тимур Какохо, Россия юристлар ассоциациясенең Татарстандагы бүлеге башкарма комитеты рәисе:

– Берләшкән Милләтләр Оешмасы уставында, һәр халык, һәр милләт үзбилгеләнү хокукына ия, дип язылган. Шуңа күрә референдум әлеге территорияләрдә яшәүчеләрнең теләге генә түгел, ә закон нигезендә расланган тулы хокукы да. Бүген без әлеге республикаларда, өлкәләрдә яшәүчеләрнең референдум үткәрү юлы белән әлеге хокукны гамәлгә ашыруларын күрәбез. Әлеге процессны җәмәгатьчелек вәкилләре, аерым алганда, әлеге субъектларның Иҗтимагый палатасы һәм бәйсез күзәтүчеләр контрольдә тотачак.

Гомумән, 2014 елны искә төшерсәк, Кырымны Россия составына кушу процессында, күпчелек бу карарны уңай бәяләде. Чөнки Кырымда да рус халкы күпләп яши иде. Бу очракта да шулай. Миңа калса, ул төбәкләрдә дә, Россия халкы да бу карарны уңай кабул итәр дип уйлыйм.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Шифалы су – Ижминводы» санаторие һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе табиб-терапевты **Газизуллин** Илдар Мәхмүт улына, «Республика махсуслаштырылган балалар йорты» дәүләт казна сәламәтлек саклау учреждениесе директорының медицина часте буенча урынбасары **Зарипова** Раушания Равил кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең колопроктология бүлекчәсе мөдире – табиб-колопроктологы **Җиһаншин** Марат Исмәгыйль улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-онкологы **Киршин** Александр Александровичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы ортопедия бүлекчәсе мөдире – табибы – травматолог-ортопеды **Кудрявцев** Алексей Игоревичка, «Татарстан Республикасында (Татарстанда) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең лаборатория эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, гомуми гигиена буенча табибы **Сафина** Гүзәл Нияз кызына, «5 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 9 номерлы поликлиникасы профилактика бүлекчәсе мөдире – табиб-терапевты (Чаллы шәһәре) **Хәйретдинова** Резеда Нәкыйп кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе хезмәт гигиенасы, радиацион гигиена һәм транспортта күзәтчелек бүлеге баш белгече-эксперты **Хисамова** Фәния Фоат кызына, «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең оештыру-методика бүлеге мөдире – табиб-статистигы **Шаматова** Альбина Фәрит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Эшләре тотрыклы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Соңгы елларда республика халкының банкларга ышанычы да арткан. Ел башыннан бирле банкларга ясалган кертемнәр күләме 6 процентка үскән. Гомумән алганда, республикада җәлеп ителгән акча күләме 1,8 трлн сумга җиткән. Шуның 800 млрд сумын халык тарафыннан ясалган кертемнәр тәшкил итә.

Рөстәм Миңнеханов китергән саннардан аңлашылганча, республиканың сәнәгать оешмаларындагы җитештерү күрсәткечләре бер ел эчендә 5 процентка арткан. «Бу шулай ук банк системасының тотрыклы эшләвен раслый торган тагын бер күрсәткеч булып тора. Авырлыкларга карамастан, ышанычлы адымнар белән алга баруыбызны дәвам итәбез. Дөрес, логистика, комплектлаштыру мәсьәләсендә кайбер кыенлыклар бар. Әмма без аларны хәл итү юлларын табабыз», – диде Президент.

Форумда төбәк банкларына күп кенә федераль программада катнашу юлларын җиңеләйтү турында да фикер алыштылар. «ВТ» хәбәрчесе белән аралашу барышында Фәнис Хөсәенов моны республика өчен иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе дип атады.

– Күп кенә эре авыл хуҗалыгы оешмалары акчаны федераль банклар аша ала. Ник дигәндә, федераль банкларга бу ставка буенча компенсация кайтару җайлырак. Төбәк банклары исә бу мөмкинлектән файдалана алмый. Шуңа форумда бу мәсьәләнең дә каралуы бик яхшы. Цифрлы инфраструктурага янаган куркынычлар турында сөйләшүләре дә көн кадагына туры килә. Күреп торабыз, финанс мошенниклык очраклары арта бара. Мошенниклар халыкның финанс белеме җитмәүдән оста файдалана. Бүген хәтта законлы финанс оешмалары да, халыкның шушы көчсез ягыннан файдаланып, аларга кирәкмәгән хезмәтләрне тагарга тырыша. Үзәк банк мондый алдау очракларын булдырмас өчен бик күп чаралар күрә. Әмма болар гына җитәрлек түгел, – ди белгеч.

Якын арада өлешчә мобилизациядә катнашучыларның кредит буенча түләүләре кичектереп торылырга мөмкин. Россия Дәүләт Думасының Финанс базары буенча комитет рәисе Анатолий Аксаков форум барышында шундый тәкъдим җиткерде.

– Кредит каникулларына кабат ихтыяҗ туды. Якын арада шул хакта закон проекты кертергә җыенабыз. Өлешчә мобилизациядә катнашучыларның күбесенең банкта кредитлары бар. Хәрби бурычларын башкарган чорда кредит түләү кыенлашачак. Безгә хәрби бурычын башкарган кеше банк алдындагы бурычлары өчен ут йотмаслык шартлар тудырырга кирәк, – диде ул.

Форум кысасында SWIFT халыкара түләү системасыннан тулысынча баш тартып, исәп-хисапларны милли валютада гына башкарырга кирәк дигән фикер дә яңгырады. «ВТБ» башлыгы Андрей Костин фикеренчә, чикләүләр кертелгәнче бу мәсьәлә алай ук кискен тормаса да, хәзер инде сүздән эшкә күчәр чак җиткән.

– Бүген бу безнең алда торган иң мөһим бурычларның берсе булырга тиеш. SWIFT системасына мохтаҗлык тудырмый торган көчле түләү системасы булдырырга кирәк. Без хәтта Евразия икътисади берлеге кысасында башкарылган исәпләүләрдә дә әле һаман SWIFT системасын кулланабыз бит. Моны туктатырга кирәк. Бездә Кытай, Казахстан кебек күп кенә илләрдәге кебек финанс хәбәрләрне тапшыру системасы бар. Безгә әнә шуннан файдаланырга кирәк, – диде Костин үз чыгышында.

Файда димәктән, белгечләр Казанда узган форумның республика өчен тагын бер зур файдасы булачак дип фаразлый. КФУның идарә итү, икътисад һәм финанс институты профессоры Игорь Кох фикеренчә, әлеге форум Татарстанга күп кенә башка эре банкларны да җәлеп итәргә булышачак.

– Татарстан – үзенең көчле банк системасы булган төбәк. Республика банк системасын, банк продуктларын үстерү белән дә ныклап кызыксына. Моннан тыш Татарстан капитал кулланучы иң эре төбәк санала. Республика үсә, үзгәрә, икътисад, авыл хуҗалыгы тармаклары үсештә. Казанда узган банк форумы, мөһим мәсьәләләр күтәрүе белән беррәттән, Татарстанга республика үсешенә ярдәм итәрлек башка эре банкларны да җәлеп итәргә ярдәм итәчәк, – ди белгеч.

Игорь Кох берочтан халыкны борчыган актуаль сорауга да ачыклык кертте. Ни өчен төп ставка төшсә дә, бәяләр үсә бирә?

– Үзәк ставка югары булганда, бәяләр үсеше акрыная. Түбән ставка исә, киресенчә, товарларның кулланылышын арттыра, нәтиҗәдә бәяләрнең артуына китерә. Бәяләр туктап тормый, һәрчак үсә. Әмма алар чамадан тыш зур тизлектә үсә башласа, Үзәк банк төп ставканы күтәрергә мәҗбүр була. Бәяләр акрын үскәндә, Үзәк банк, җитештерүчеләргә ярдәм йөзеннән, төп ставканы да бераз төшерә. Бүген бәяләр үсүе акрынайды. Ул гына да түгел, соңгы бер-ике айда гомумән дифляция күзәтелә. Шуңа күрә Үзәк банк та төп ставканы төшерде, – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз дүртенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары итеп Е.А. Варакинны билгеләп куюны килештерү турында.
3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым комитетлары составларындагы үзгәрешләр турында.
5. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 12 августындагы 40 номерлы килешүне раслау хакында.
6. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 342-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 341-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең 81 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 330-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 312-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «2023 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 335-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
11. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 324-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында» 323-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 325-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 307-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
15. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 320-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 332-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 321-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 326-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 һәм 40 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 336-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
20. «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 337-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
21. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 333-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
22. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 309-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
23. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 319-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
24. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 322-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
25. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 327-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
26. «2023 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 329-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
27. «2023 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 328-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
28. 2021 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
30. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 183172-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хокукый статусын регламентлаштыра торган коррупциягә каршы законнарны камилләштерү өлешендә).
31. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.
32. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 190826-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 14, 84, 85 һәм 153 статьялары нигезләмәләрен 414-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын исәпкә алып төгәлләштерү өлешендә).
33. «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 172859-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның торак шартларын яхшыртуны тәэмин итү өчен бирелгән федераль бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру максатларында).
34. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 164411-8 номерлы федераль закон проекты турында (чит ил гражданнарын, шулай ук үзләренә бәйсез сәбәпләр аркасында туктатылмаган чит дәүләт гражданлыгы да булган Россия Федерациясе гражданнарын дәүләт хезмәтенә яисә муниципаль хезмәткә алу мәсьәләләрен җайга салу хакында).
35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.35 статьясына үзгәреш кертү хакында» 149604-8 номерлы федераль закон проекты турында (хайваннарның яисә үсемлекләрнең сирәк очрый торган яисә бетү куркынычы янаган төрләрен юкка чыгарган өчен административ җаваплылыкны ачыклау өлешендә).
36. Хөкүмәт сәгате: «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү буенча балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеге турында».
37. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1561-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп өч елга түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:

8 нче суд участогына – Фәхретдинова Айгөл Данис кызын.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1562-VI ДС

Е.А. Варакинны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары итеп билгеләп куюны килештерү турында

Татарстан Республикасы Президентының Е.А. Варакинны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары итеп билгеләп кую турындагы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 18 һәм 49 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Варакин Евгений Анатольевичны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары итеп билгеләп кую белән килешергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1563-VI ДС

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

САРЫ АЙНЫҢ СЕРЛӘРЕ

Көз быел ялындырып тормады, төп-төгәл үз вакытында килде. Әлеге фасылның үз холкы, үзенчәлеге бар. Халыкның да көз фасылына аерым мөнәсәбәте бар. Ә сез көзнең холкын яхшы беләсезме? Үзегезне сынап карагыз әле.

1 Көзнең иң озын ае?
а) сентябрь;
б) октябрь;
в) ноябрь.

2 «Әбиләр чуагы» гадәттә кайсы айда була?
а) сентябрь;
б) август;
в) октябрь.

3 Көз көне нәрсәне саныйлар?
а) песи;
б) чеби;
в) бозау.

4 Көзен кайсы агачның яфраклары яшел килеш кала?
а) зирек;
б) өрәңге;
в) сирень.

5 Бу шигырь юлларының авторы кем?
Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана.
– Бу кайчак була?
а) Габдулла Тукай;
б) Разил Вәлиев;
в) Ләбиб Лерон.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. б); 4. в); 5. а).

КИҢӘШ

Балага өй эшләрен эшләргә ярдәм итү буенча киңәшләр.

Балага эш өстәле булдырыгыз. Дәресләрне бары тик шул өстәлдә генә әзерләргә, аны һәрвакыт тәртиптә тотарга өйрәтегез. Эш урынында артык бернәрсә дә булырга тиеш түгел.

Балага өй эшләрен мөстәкыйль эшләргә өйрәтегез. Ярдәм кирәк булганда гына сезгә мөрәҗәгать итсен. Сабыр булыгыз, баланың хаталарын күреп ачуланмагыз, ә аларны табарга, төзәтергә, каян килеп чыкканын аңларга ярдәм итегез. Баланы мактап та алыгыз, үз көченә ышанычын арттырыгыз.

Өй эшләрен эшләү гадәткә керергә тиеш. Бу гадәтне беренче сыйныфтан ук формалаштырырга кирәк. Эшне бер үк вакытта башларга өйрәтегез. Мәктәптән кайткач та баланы дәрес әзерләргә утыртмагыз, 2–3 сәгать ял итеп алсын. Дәрес әзерләү өчен иң яхшы вакыт – көндезге сәгать 3тән 5кә кадәр, кич белән дәрес әзерләргә киңәш ителми.

Өй эшләрен катлаулыгы буенча аерып эшләргә киңәш ителә. Зур биремнәрне өлешләргә бүләргә, көндәлеккә язганда, аеруча мөһимнәрен (күбрәк вакыт таләп иткәннәрен) билгеләп барырга кирәк. Балагыз беренче чиратта иртәгә үк тапшырасы катлаулырак өй эшләрен әзерләсен, аннары инде калган дәресләргә тотынсын.

АЙЗА ГАЛИЕВА:

«СӘХНӘДӘ ҮЗЕМНЕ ИРКЕН ТОТАМ, Ә ТОРМЫШТА МИН ОЯЛЧАН»

Җырлый, клипларда төшә, актерлык түгәрәгенә йөри, матурлык конкурсларында да катнашырга өлгерә. Бүген бездә кунакта – күпкырлы талант иясе, булачак артист Айза ГАЛИЕВА.

:: Айза, вокал белән ничә яшьтән бирле шөгыльләнәсең инде?
– Мин балалар бакчасына йөргәндә җырлый башладым. Ул вакытта миңа биш яшь иде. Миңа ошап китте һәм аннары моның белән профессиональ рәвештә шөгыльләнә башладым. Без әле ул вакытта Түбән Камада яши идек. Игорь Крутой академиясендә кастинг оештырылачагын ишеткәч, шунда барып карадым. Кастингны узып, атнага өч тапкыр әти белән әни мине шунда йөрттеләр. Аннары без Казанга күчтек.

:: Нинди җырлар башкарасың?
– Репертуарымда күбрәк татар җырлары. Халык җырларын да, эстрада җырларын да бик яратып башкарам. Соңгы «Дәү әни, дәү әти» җыры махсус минем өчен язылды. Мәскәүдә конкурсларда чыгыш ясаганда, рус һәм инглиз телләрендә җырлыйм.

:: Конкурслар дигәннән, аларда катнашу ошыймы үзеңә?
– Матурлык, җыр конкурсларында катнашырга яратам. 2020 елда Мәскәүдә узган «Мини-мисс Россия» һәм «Милләт горурлыгы» Бөтенроссия талантлар фестивалендә Татарстанны тәкъдим итеп, гран-при яуладым. Быел беренче тапкыр «Созвездие – Йолдызлык» конкурсында катнаштым. Анда суперфиналга үттем. «Новая волна»да сайлап алу турын үтеп, ярымфиналга җиттем. Тагын да тырышып, финалга кадәр барып җитәсем килә.

:: Җырларга нәрсә илһамландыра сине?
– Сәхнә. Яңа җырны тыңлап карагач, аны җырлап булырмы, башкарып чыга алырмынмы дип борчыла башлыйм. Тик соңыннан үземне тынычландырам, җайлап кына өйрәнәм. Сәхнәгә чыккач, борчылу бөтенләй онытыла. Тормышта мин оялчан, ә сәхнәдә ачылам, күп кеше алдында чыгыш ясарга яратам. Вокал белән генә түгел, хореография, актерлык осталыгы белән дә шөгыльләнәм әле мин.

:: Шөгыльләрең шактый күп икән, ә киләчәктә кем булырга телисең?
– Җырчы буласым килә. Академиядә актерлык осталыгы түгәрәгенә дүртенче ел йөрим. Актриса булу, төрле фильмнарда төшү теләге дә бар.

КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ
- Айзага – 9 яшь;
- ул Казанның 57 нче мәктәбендә 3 нче сыйныфта укый;
- Игорь Крутой академиясендә бишенче ел шөгыльләнә;
- киләчәктә йә җырчы, йә актриса булырга хыяллана.

:: Иҗат юлында синең өчен кем үрнәк?
– Рифат Зарипов. Аның белән без быел «Балалар премиясе»ндә бергә җырладык. Шулай ук вокал буенча педагогым, «Ямьле» төркеме солисткасы Альбина Казыханова.

:: Татар җырчыларыннан тагын кемнәрне тыңлыйсың?
– Салават абыйны һәм Зәйнәб апа Фәрхетдинованың улы Акбулатны. Без аның белән дуслар да әле, гел аралашып торабыз.

:: Мәктәптә уңышларың ничек соң? Укырга вакытың каламы?
– Мәктәптә «дүртле» һәм «бишле» билгеләренә генә укыйм. Иң яраткан дәресем – татар теле. Шөгыльләрем укуга комачауламый. Репетицияләр, чыгышлар булса, мәктәптә моңа каршы килмиләр. Конкурсларга да җибәрәләр. Мәктәптәге чараларда үзем дә бик теләп катнашам.

:: Ә буш вакытларыңда нәрсәләр белән шөгыльләнәсең?
– Буш вакытта бисердан кул эшләнмәләре ясарга, укырга, рәсем ясарга яратам. Йөзүгә дә йөрим. Ул сулыш өчен бик файдалы, ә бу җырлаганда бик мөһим. Өч яшьлек сеңлем Азизәне дә карарга яратам. Ул минем бөтен җырларымны белә.

:: Иң зур теләгең нинди?
– Кешеләрнең дус-тату, бер-берсе белән ачуланышмыйча яшәүләрен телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Хикәя

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН

ГИПНОЗЧЫ МАЛАЙ

Әтисе Марсельгә тизлеген үзгәртеп була торган велосипед алган. Ул аны авылга да алып кайткан. Әй мактанды инде шуның белән! Тизлеген егерме бер төрле итеп үзгәртеп була, имеш! Ә үзе ярышканда һаман иң артта кала. Су коенырга барганда да, якындагы үзәнлеккә җиләк җыярга чыккач та Ринат Марсельне озаклап көтеп тора иде. Үзе сер бирмәгән була:

– Сәпиттә тиз йөрү йөрәккә зыянлы. Әтием әйтте! – ди ул.

Ә беркөнне кич белән Ринат, Марсель һәм күрше малае Раил капка төбендә сөйләшеп утырдылар.

– Малайлар! Мин бер шәп «гипноз» беләм. Әйдәгез эшләп карыйбызмы? – диде Марсель.

Бөтен нәрсә белән дә кызыксынучан Раил шатланып риза булды:

– Әйдә! Ә ничек соң ул?

– Менә болай эшлибез: син тирән итеп илле тапкыр сула. Аннары, мин әйткәч, туктарсың, – диде Марсель.

Раилнең еш-еш сулыш алганын күзәткән Марсель кинәт аның күкрәгенә ике куллап басты…

Шуннан соң Раил берни дә хәтерләми. Төрткәли торгач кына уянып китте ул.

– Әй, ник уяттыгыз инде? Рәхәт иде бит!

– Ярый әле уяндың, – диде куркуыннан агарынган Ринат. – Үләсең дип торам.

– Бернәрсә дә булмый аңа, – диде Марсель. – Казанда бер малайга «гипноз» ясадык та директор бүлмәсенә кертеп җибәрдек. Директор үзен килеп кочаклаган малайны күреп хушсыз калган… Әйдә, Ринат, сиңа да ясыйбыз!

– Юк инде, – диде Ринат, калтыранган тавышын тыярга тырышып.

Гипнозлау тиз арада бөтен авыл малайларына таралды. Барысы да гипноздан соң «очып» йөреп чыктылар. Марсель алардан рәхәтләнеп көлде:

– Әй сез, йомшаклар! Ә мине гипнозлый алмадылар. Мин – көчле! – дип мактанды ул.

Ә беркөнне Рәшит:

– Әйдә, Марсель, сиңа да «гипноз» ясап карыйк әле. Көчлеме син, куркакмы, шуннан белербез, – диде.

Марсель ни дияргә белмәде. Тик куркак булып саналасы килмәгәнгә, ризалашты.

…Күкрәгенә Рәшит нык куллары белән каты итеп басуга, Марсель, күзләре ярым йомык килеш, кулларын канат сыман җилпеп, чайкала-чайкала китеп барды. Моны күргән авыл малайлары тәгәрәп көлде. Бары Ринат кына, нидер сизенеп, Марсель артыннан йөгерде. Кычкырып та карады, битләрен дә чәбәкләде: әмма Марсель уянмады.

– Егетләр, ярдәм итегез, Марсель үлә! – дип кычкырды агарынган Ринат.

Шикләнеп калган малайлар Марсельне селкеткәләргә керештеләр. Тик юкка: Марсель тирән йокыда иде. Иң ахырдан Рәшит, кулларын йодрыклап, аның ияк төбенә кундырды.

…Марсель елап уянды. Башта авыртудан еласа, аннары, үзенең хурлыкка калуын аңлап, ныграк үкси башлады.

– Менә сиңа «батыр»! – дип көлде Рәшит.

– Киттек, малайлар, рәхәтләнеп еласын! – диде Раил, мыскыллап.

Күз яшьләренә буылган Марсель янында бары Ринат кына калды. Шәһәр кунагы елаудан туктап тынычлангач, сүзсез торган Ринат көлеп җибәрде:

– Вәт шәп «гипноз» булды бу! Малайлар булышмаса, мәңге уянмаска да мөмкин идең! – диде.

Марсель дәшмәде. Үзенең хурлыгын юарлык сүзләр таба алмады…

Сорау – җавап

«Мәктәпкә барасым килми»

Кызым быел беренче сыйныфка барды. Тик мәктәпкә ияләшеп бетә алмый. Кайткач елый, «мәктәпкә барасым килми», ди. Нишләргә?

Алсу Г., 32 яшь

Надежда МӘХМҮТОВА, балалар психологы:
– Бу – нормаль күренеш. Һәр баланың мәктәпкә ияләшү чоры төрле. Бала әле җайлашмаган, адаптация чорын узмаган яисә ул әле мәктәптә дуслар табып өлгермәгән булырга мөмкин. Мондый очракта тынычлыкны сакларга һәм балага ярдәм итәргә кирәк. Бала мәктәптән кайткач, аның белән сөйләшегез, хәлләрен сорашыгыз, саф һавада йөреп керегез. Өй эшләрен кайтуга ук эшләтмәгез. Шулай ук, баланы әкренләп мөстәкыйльлеккә дә өйрәтергә мөһим. Иң яхшысы – бала белән ышанычлы әңгәмә. Шул вакытта барысы да килеп чыгачак.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 340

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+